РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 октябрь 2025 ел Буа шәһәре № 4-2

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында «Бердәм Россия» партиясенең депутат фракциясен төзү турында

Депутат И. Ф. Еремеевның бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында «Бердәм Россия»партиясенең депутат фракциясен төзү турындагы хәбәрнамәсен карап, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 18 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы Регламентының 49.1 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында депутатлар – «Бердәм Россия» сәяси партиясе әгъзалары составында «Бердәм Россия»партиясенең депутат фракциясен төзергә.
2. «Бердәм Россия» партиясенең депутат фракциясен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының депутат фракцияләре реестрына кертергә.
3. «Бердәм Россия» партиясенең депутат фракциясе җитәкчесе И.Ф. Еремеевка Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы депутатларына фракция эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында «Бердәм Россия» партиясенең депутат фракциясе составындагы үзгәрешләр турында мәгълүмат бирүне йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов